Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2021 елның 10 ноябре, № 3

**«Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2021 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Түбән Казаклар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын билгеләргә. Түбән Казаклар авылы, М.Җәлил урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары , 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-юлларда чокырларны ямау, вак таш җәю һәм асфальт җәю, смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- Түбән Казаклар авылы зиратын коймалар һәм койма буяу өчен материал сатып алу; Түбән Казаклар авылы зираты коймасын реконструкцияләү; смета документациясе төзү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Олыяз авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов

ОГРН 1021607754651
ИНН 1623001879